СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«24» март 2017 ел** **№ 113**

**Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында**

«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2015 елның 22 гыйнварындагы 313 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Уставына (2015 елның 28 маендагы 335 номерлы, 2015 елның 26 октябрендәге 11 номерлы, 2016 елның 19 февралендәге 28 номерлы, 2016 елның 14 декабрендәге 91 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1) 6 статьяның 1 өлешендәге 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«14) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (өстәмә белем бирүдән тыш, аны финанс ягыннан тәэмин итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүне оештыру), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә балаларның тормыш һәм сәламәтлеген тәэмин итү чараларын да кертеп гамәлгә ашыру;»

**2) 20 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

« 1) муниципаль берәмлек уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, муниципаль берәмлек уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, әлеге уставны әлеге норматив хокукый актларга туры

китерү максатларында Россия Федерациясе субъекты конституциясе (уставы) яисә законнарын төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;»

**3) 46 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«4. Район башлыгы урынбасары район Советы регламентында билгеләнгән вазыйфаларны бүлү нигезендә вазыйфаларны үти, район башлыгының йөкләмәләрен үти, ә вакытлыча юкка чыккан очракта (авыруга яисә отпускка бәйле рәвештә), сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә аны суд карары буенча процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта район башлыгы вазыйфаларын башкара.

**4) 47 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (өстәмә белем бирүдән тыш, аны финанс ягыннан тәэмин итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүне оештыру), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук каникул чорында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча чараларны үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыру;»

**5) 52 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:**

«3. Район башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә суд карары буенча аны сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары башкара.»

**6) 89 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«3. Район уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проекты, аларны караган көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, район Советы тарафыннан күрсәтелгән Устав проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибенең, район Советының күрсәтелгән карары проектының бер үк вакытта бастырып чыгарылуы (халыкка җиткерелүе) һәм шул ук вакытта гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибенең рәсми басылып чыгуы (халыкка җиткерелүе) белән бастырып чыгарылырга тиеш. Район Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук күрсәтелгән үзгәрешләр Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе субъекты конституциясе (уставы) яисә законнарын әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе субъекты законнары

нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә кертелгән очракта гражданнарның аны фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми;»

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм гражданнарның 1 нче кушымта нигезендә фикер алышуда катнашуын расларга.

3. 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашуын расларга.

4. Әлеге карарны «Арча хәбәрләре» район газетасында яки Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга. (http:pravo.tatarstan.ru).

5. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Осина Л.М. - 9 нчы Яңа Кенәр сайлау округы буенча депутат, төркем җитәкчесе;

2) Г.Р. Заһидуллина - 2 нче Иске Чүриле сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3) Вафина Р.Р. - 9 нчы Урта Курса сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы.

6. Арча район Советы депутатларының Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына төзәтмәләре рәвешендә тәкъдимнәре эшче төркемгә 2017 елның 27 апреленә кадәр кертелә дип билгеләргә.

7. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре Ф.и.а.и., туган елы, адресы күрсәтелеп, Арча

шәһәре, Совет мәйданы, 14 нче йорт адресы буенча язма рәвештә эшче төркемгә җибәрелә дип билгеләргә.

8. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны Арча район Советының кече залында 2017 елның 27 апреленә билгеләргә.

9. Эшче төркемгә Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына Арча район Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, аны 2017 елның 28 апреленә кадәр Арча район Советы каравына кертергә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе                                        И.Г. Нуриев

*Арча район Советының*
*24.03. 2017ел, №113 карарына*
*1 нче кушымта*

**Арча муниципаль районы Уставында үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу**
**ТӘРТИБЕ**

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча тәкъдимнәр язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Арча район советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 14 йорт:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адресы, эш урыны, укулар) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр әлеге карар «Арча хәбәрләре» район газетасында басылып чыккан көннән соң эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар язмача яки почта аша.түбәндәге адрес буенча бирелә: 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 14 йорт

Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен «Арча муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Советына һәм башлыгына тапшырыла.

Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары,
район Советы рәисе урынбасары Л.М. Осина

*Арча район Советының*
*24.03.2017 ел,№ 113*
*карарына 2 нче кушымта*

**Арча муниципаль районы Уставы проекты буенча**
**гавами тыңлаулар үткәрү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын карау буенча гавами тыңлаулар

Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставының 15 статьясы нигезендә башкарыла.

2. Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, прокуратура, белгечләр, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр, белгечләр, кызыксынган затларны чакырып үткәрелергә мөмкин.

3. Ачык тыңлауларда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының һәр кешесе катнашырга хокуклы.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

5. Ачык тыңлауларда Арча муниципаль районы башлыгы яки Башлыгы урынбасары рәислек итә.

6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен, секретариат җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында гавами тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән Устав проектын эшләү буенча эшче төркем җитәкчесе чыгыш ясый.

9. Төп докладтан соң сүз гавами тыңлауларда катнашырга чакырылган катнашучыларга бирелә.

10. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашучылар гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чиратлылык тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

11. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары расланган регламент нигезендә дәвам итәргә тиеш.

12. Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң рәис рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

13. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14.Гавами тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны тыңлаулар үткәрелә торган бинадан төшереп калдыруны таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче гавами тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

17. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе секретариат җитәкчесе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Арча район Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

18. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә гавами тыңлаулар секретариаты тарафыннан әзерләнә һәм халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Ачык тыңлаулар үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Арча район Советы тарафыннан башкарыла.

Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары,
район Советы рәисе урынбасары Л.М. Осина